ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.01.2021 с.Старое Дрожжаное №26

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге генераль планы проектын килештерү буенча Килештерү комиссиясе төзү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы, Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2016 елның 21 июлендәге 460 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 28 декабрендәге 10-53/16124 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең генераль планы проекты белән килешмәве турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсенә нигез булып торган каршылыкларны җайга салу максатларында, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясен төзергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясенең эш тәртибен расларга (1 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).

4. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) https://drogganoye.tatarstan.ru/.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Д.А.Сатдинов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның «29» 01 №26
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча Килештерү комиссиясе эшчәнлеге тәртибе**

1. Килештерү комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары проектларын, территориаль планлаштыру документлары проектларын килештергәндә килештерү тәртибен, килештерү комиссиясе составын һәм эш тәртибен раслау турында» 2016 елның 21 июлендәге 460 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына таянып эш итә.
2. Килештерү комиссиясе үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка кызыксынган затлар белән үзара бәйләнештә алып бара.
3. Килештерү комиссиясенең максималь эш вакыты аны төзү датасыннан ике айдан да артмаска тиеш.
4. Килешү комиссиясен төзү датасы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы рәсми сайтында эшчәнлек тәртибен һәм составын раслау турында карарын рәсми бастырып чыгару көне булып тора.
5. Килешү комиссиясе утырышын аның рәисе оештыра һәм алып бара, ә ул булмаганда - килештерү комиссиясе рәисе урынбасары.
6. Комиссия кирәк булган саен җыела.
7. Комиссия әгъзаларына Комиссиянең киләсе утырышының датасы, вакыты һәм урыны турында соңга калмыйча 5 (биш) көн эчендә хәбәр ителә.
8. Килештерү комиссиясе утырышларында комиссия әгъзалары катнаша, ә кирәк булганда, Килештерү комиссиясе утырышларында гамәлдәге законнар нигезендә башка органнар вәкилләре дә катнаша ала.
9. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең генераль планы проектына карата искәрмәләр биргән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкилләре комиссия эшендә язмача позицияләр бирү юлы белән катнашалар.
10. Килештерү комиссиясе утырышы, әгәр анда исемлек составының кимендә 50% ы катнашса, хокуклы дип санала.

11. Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсенә рәис һәм сәркатип кул куя.

12. Килештерү комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карарга каршы тавыш биргән Килештерү комиссиясе әгъзалары аерым фикерне рәсмиләштерә алалар, ул беркетмәгә кушылачак һәм аның аерылгысыз өлеше булачак.

13. Бердәм комиссия карарлары утырыштагы комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

14. Килештерү комиссиясе нәтиҗәләре Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсендә чагылдырыла.

15. Үз эше нәтиҗәләре буенча килештерү комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

15.1. Территориаль планлаштыру документы проектын әлеге проект белән килешмәү өчен нигез булып торган барлык искәрмәләрне исәпкә алган үзгәрешләр кертеп килештерергә.

15.2. Баш тарту турында Карар кабул итүгә нигез булган сәбәпләрне күрсәтеп, территориаль планлаштыру документы проектын килештерүдән баш тартырга.

15.3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы кисәтүләрен төшереп калдыру юлы белән территориаль планлаштыру документы проектын аңа төзәтмәләр кертмичә килештерергә.

16. Килештерү комиссиясе үзенең эш нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгына җибәрә:

16.1. Тәртипнең 15 пунктындагы 15.1 пунктчасында күрсәтелгән карар кабул иткәндә, территориаль планлаштыру документы проекты, Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе белән бергә, аңа кертелгән үзгәрешләр белән.

16.2. Тәртипнең 15 пунктындагы 15.2 пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгәндә, территориаль планлаштыруның килештерелмәгән проекты, Килешү комиссиясе беркетмәсе, шулай ук текст рәвешендәге материаллар һәм килештерелмәгән мәсьәләләр буенча карталар рәвешендәге материаллар.

Әлеге Тәртипнең 15.2 пунктчасында күрсәтелгән документларда һәм материалларда түбәндәгеләр булырга мөмкин:

- килештерелмәгән мәсьәләләр буенча материалларны территориаль планлаштыру документы проектыннан төшереп калдыру турындагы тәкъдимнәрне (шул исәптән килештерү вакытына кадәр килештерелмәгән проектларны теркәү максатларында тиешле картада аларны чагылдыру юлы белән);

- Тәртипнең 15 пунктындагы 15.1 пунктчасында күрсәтелгән килештерү планы, территориаль планлаштыру документын тиешле үзгәрешләрне территориаль планлаштыру документына кертү турында тәкъдимнәр әзерләү юлы белән раслаганнан соң.

17. Килештерү комиссиясе тарафыннан бирелгән беркетмәләр һәм материаллар нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге генераль планы проектын раслау өчен яисә раслаудан баш тарту турында һәм аны эшләп бетерү өчен килештерелгән яисә билгеләнгән өлештә килештерелмәгән проектны җибәрә.

18. Килештерү комиссиясе адресына язма рәвештә килә торган гаризаларга һәм запросларга җаваплар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда бирелә.

19. Килештерү комиссиясе карарларына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның «29» 01 № 26
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясе**
**составы**

| | |
|---|---|
| 1. Сатдинов Д. А. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе - Комиссия рәисе. |
| 2. Багаутдинов Р. Р. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге башлыгы - Комиссия рәисе урынбасары. |
| 3. Фатхеев Ф. Р. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеге баш белгече - Комиссия секретаре. |
| Комиссия әгъзалары: | |
| 4. Залялов А. Ф. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| 5. Абдреев И. Т. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе. |
| 6. Вәкаләтле зат (килешү буенча) | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы |
| 7. Вәкаләтле зат (килешү буенча) | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 8. Сосновский С.В. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең генераль планы проектын эшләп чыгаручы вәкиле «Максима» ҖЧҖ. |